**Слайд №1** Титульник

**Слайд №2”Безнең яңа мәктәп”** Хөрмәтле коллегалар! Барыгызга да мәгълүм булганча, “Безнең яңа мәктәп” милли инициативасы мәгариф өлкәсендә 5 юнәлешне билгеләде. Шуларның берсе: сәләтле балаларны үстерү системасы булдыру,укучыларның мөмкинлекләрен ачу.

**Слайд №3 Актуальлек** Һәр бала шәхес, яки иҗади шәхес.Аны ничек үстерергә? Бу сорау әлеге көндә безне,укытучыларны, бик борчый. Интернат-мәктәп кысаларында яшәү урыннары, тәрбияләү шартлары төрле булган балалардан яңа төр социаль берлек формалаштырып,аларның белем дәрәҗәсен ачыклап, тел компетенцияләрен үстереп,туган телне өйрәнүгә омтылыш кына түгел, аңа тирән мәхәббәт һәм ихтирам хисе тәрбияләү, бигрәк тә мәгариф системасының өстенлекле юнәлешләре үзгәрү кичергән вакытта,актуаль булып тора.

**Слайд №4** Алда әйтеп кителгәннәрдәнчыгып, сезнең игътибарга тәкъдим ителгән эшебезнең **максаты**: һәр баланың сәләтен ачуга шартлар булдыру, аны туган телен яхшы белүче,яратучы иҗади шәхес итеп тәрбияләү.

**Бурычлар**: аларның белем дәрәҗәсен ачыклап, тел компетенцияләрен үстерү; туган телне өйрәнүгә омтылыш кына түгел, аңа тирән мәхәббәт һәм ихтирам хисе тәрбияләү;баланың табигать тарафыннан бирелгән сәләтен үстереп, аны иҗади шәхес буларак тәрбияләү.

Эшчәнлегебезнең нигезен профессор Әхмәт Зәки улы Рәхимовның үстерелешле укыту методикасы, академик Мирза Исмаил улы Мәхмүтовның “Мәктәптә проблемалы укыту”, Русиянең атказанган укытучысы Вил Суфиян улы Казыйхановның “Әхлак дәресләре” дигән хезмәтләре тәшкил итә.

**Слайд №5 Схема** Эшчәнлегебезнең төп юнәлешләрен шартлы рәвештә 4 этапка бүлеп була: мәктәпнең мөмкинлекләрен һәм баланың мотивациясен

( теләкләрен) ачыклау; мониторинг һәм диагностика, укучы һәм укытучы эшчәнлеге,бәяләү.

**Слайд №6 Беренче этап** Иң беренче чиратта, балалар мәктәпкә килгәч,диагностика үткәрелә.Игътибарыгызга шуларның берничәсен тәкъдим итәбез.”Татар телен ни өчен өйрәнәм?” дигән сорауга нинди җаваплар булды? “Бөтен таләпләрне дә төгәл үтәргә тырышам”-79/86, “туган телемне тирәнрәк өйрәнү теләге”-49/52, “дәрестәге эшчәнлектән канәгатьлек табам”-63/73, “мине белемнәр генә түгел, аны табу ысуллары кызыксындыра”-64/72,”дәрес мавыктыргыч үтә”-52/78, “иҗади эшләрне башкарганда канәгатьлек табам”- 42/61.Татар теле дәресләрендә иҗади фикерләү теләге булган укучылар саны да елдан- ел арта бара.Укучылар дәрескә нинди кәеф белән килә соң? Бу сорауга җавап бирүчеләрнең 72% кызыксыну белән,

27,5%- күтәренке күңел, 0,5%- курку, битарафлык белән дип җавап бирде. Бу телне белмәүдән килә, әлбәттә.

**Слайд №7 Икенче** Бала шәхесен үстерүгә юнәлтелгән бар шартлар да мәктәптә бар. Мәктәпкә хас үзенчәлек тә ( специфика) моңа ярдәм итә:балалар белән тәүлек әйләнәсенә бергә булу укытучыга балалар һәм аларның ата- аналары белән тыгыз бәйләнештә булу мөмкинлеге тудыра. Ата- аналар да безнең актив ярдәмчебезгә, хезмәттәшебезгә әйләнделәр. Балаларының туган телләрен өйрәнүгә уңай караш формалаша.Күпчелеге:"Туган телне өйрәнү кирәк,"- дип җавап бирә.

Иҗади сәләтне үстерү, укучының күңел дөньясын тиешле юнәлештә үзгәртү өчен укытучы үзе дә иҗади шәхес булырга тиеш.Укытучы үзе эзләнми икән, балаларга белем орлыгын сала алмый.Шуңа күрә һәрдаим тикшеренү эшләре, мәкаләләр,дәрес эшкәртмәләребез матбугат битләрендә дөнья күрә. Укучыларыбызның иҗади эшләре дә "Башкортстан укытучысы","Әллүки" журналларында басыла.

Балаларның туган телне өйрәнүдә кечкенә уңышлары да стимуллаштырыла.Олимпиадаларда, конкурсларда, бәйгеләрдә җиңү яулаган гына түгел, актив катнашкан укучыларыбызны һәр ел саен Башкортстаныбыз буйлап сәяхәт көтә.Ел йомгаклары буенча сәләтле укучылар җыенында мондый балалар кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

Үзебезнең үстерелешле дәресләр системасы бар. Уку мәсьәләсен кую аша да балаларны кызыксындыру юлларын эзлибез. Ул еш кына дәрестә проблемалы ситуация тудыручы отышлы метод булып тора.

Эшчәнлегебезнең төп шартларының берсе- "шатлык аша укыту һәм тәрбияләү". Һәр дәрестә стимуллар системасы булдырырга тырышабыз Яшерен түгел, һәр баланың аң-белем дәрәҗәсе һәм мөмкинлекләре төрлечә. Дәрестә һәр укучыны кызыксындырып җибәрергә тырышабыз: бу кызык, бу минем фикерем, бу аңлаешлы, мин моны үзем ясадым, мин дә эшли алам, мин дә сәләтле кебек сүзтезмәләр еш яңгырый.

**Слайд №8 Өченче этап** Татар теленә өйрәтү дигән сүз укучының дәрестә генә түгел, дәрестән тыш эшчәнлеген дә үз эченә ала.Шуңа күрә асылда без 3 юнәлеш күзаллыйбыз: дәрес, дәрестән тыш эшчәнлек һәм фәнни- тикшеренү эшчәнлеге. Укучының иҗат итү сәләте, күп очракта, дәрестә ачыла.Яңа дәүләт стандартлары таләп иткәнчә, дәрестә без баланы фикерләргә өйрәтәбез. Ә фикер йөртү- сораудан башлана.Үсеш дәресе сорарга һәм эзләнергә өйрәтә. "Нигә?" дигән сорау дәресләребездә еш яңгырый.Дәресне тикшеренү- эзләнү методы белән алып барабыз: "төшендем-истә калдырдым-үз фикеремне әйтә алам- алынган белемнәрне гамәлдә куллана алам" дигән калып буенча эшлибез.Укучыларга төрле алгоритмнар,схемалар тәкъдим итәбез.Сүзләрнең әйтелешенә һәм уку

техникасына зур игътибар бирәбез. Татар теленә өйрәтүгә һәм балаларның иҗади активлыгын үстерүгә юнәлтелгән дәрестән тыш чаралар ( викторина, бәйге, әдәби- музыкаль кичәләр, якташ язучылар белән очрашу) ярдәм итә. Әйткәндәй, мондый чаралар безнең мәктәптә бик еш үткәрелә. Күптән түгел узган”Әллүки” журналы хезмәткәрләре белән очрашу да, “Ач, шигърият, серләреңне” кичәсе, якташ язучыларыбызның әсәрләрен сәхнәләштерү бәйгесе һәм алар белән очрашулар да- моның ачык дәлиле.Мәктәптә “Тамчылар” дип исемләнгән әдәби түгәрәк эшли.Балалар кызыксынып йөри .

Татарстан Республикасының Баулы шәһәре татар гимназиясе белән бәйләнешләр булдырдык.

**Слайд №9 Мониторинг һәм диагностика** Метод һәм алымнарның сыйфатын билгеләү өчен безнең тарафтан мониторинг һәм диагностика системасы булдырылды.Ул төрле формаларны үз эченә ала.

**Слайд №10 Нәтиҗәләр** шатландырырлык: уку сыйфаты үткән уку елында 68% тәшкил итсә, бу уку елының беренче яртыеллыгында 75 % кадәр җитте. Әйтеп кителгәннәрне дәлилләүче тагын бер уңай күрсәткеч: татар теле һәм әдәбияты буенча фәнни- тикшеренү эшчәнлегенең җанланып китүе.Русия, Республика, район күләмендә үткәрелгән конференцияләрдә укучыларыбыз уңышлы чыгыш ясап килә. Димәк, телгә кызыксыну арта дигән сүз.

**Слайд №11 Грамоталар** Мәктәптә бүгенге көндә 355 бала белем ала.Шуларның 252 татар милләтеннән. Алар барысы да туган телен өйрәнә. Бу үткән ел күрсәткечләре белән чагыштырганда күпкә артыграк. Гомумән, мәктәптә туган телдә сөйләшү гадәти күренешкә әйләнде. Димәк, эшебез бушка китмәгән !

Безнең мәктәп нигезендә эксперименталь мәйданчык ачу мөмкинлекләрен карау өчен Башкортстан Республикасы мәгариф министрлыгына мөрәҗәгать итү уйлары белән яшибез. Чөнки мәктәп педагогик, тел бәйләнешләре, милләт-ара коммуникация аспектында уникаль берлекне тәшкил итә һәм безне процессның үсеше, нәтиҗәсе кызыксындыра. Министрлык тарафыннан хуплау табырбыз дигән фикердә калабыз.

**Слайд №15 Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!**